ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел.3-02-22. Факс 3-13-44

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

КАРАР
от 10.10.2018г

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР-251

**Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртү, муниципаль маршрутларын үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукын алу өчен ачык конкурста катнашучырның гаризаларын бәяләү өчен критерийлар шкаласын раслау” турында**

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законы, “Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты Уставы” 2007 нче елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законы, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 4 нче статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Актаныш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибен расларга (1нче кушымта).
2. Актаныш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларын үзгәртү һәм гамәлдән чыгару тәртибен расларга (2 нче кушымта).
3. Актаныш муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукын алу өчен ачык конкурста катнашу гаризаларын һәм критерийларны бәяләү шкаласын расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.И Гариповка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы — А.И.Тимиров